**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4388**
**04.09.2020**

Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5950 номерлы карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5950 номерлы карары (2016 елның 27 июнендәге 3269 номерлы, 2017 елның 30 гыйнварындагы 394 номерлы, 2017 елның 29 сентябрендәге 5872 номерлы, 2018 елның 28 апрелендәге 2398 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6593 номерлы, 2020 елның 22 маендагы 2406 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында Дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм тормышка ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы карары;»;

2) 2.5 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гариза (1 нче кушымта);

2) гариза бирүче гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспортының яки шәхесне раслаучы башка документларының күчермәләре;

3) гариза бирүче гражданның гаилә составы турында документларның күчермәләре (туу турында таныклык, язылышу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б.);

4) торак законнары нигезендә, гариза бирүче гражданны яисә аның гаилә әгъзасын чиратсыз торак урын бирү хокукына ия гражданнар категориясенә кертергә нигез бирә торган документлар:

- медицина оешмасыннан медицина белешмәсе – гражданның гаилә составында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган исемлек буенча, аның белән бер фатирда бергә яшәү мөмкин булмаган хроник авыруның авыр төре белән интегүче авыру булганда;

- опека һәм попечительлек органнарыннан опекун билгеләү турында белешмә - исәпкә алу турында гариза хокукка сәләтсез граждан исеменнән эш итүче опекун тарафыннан имзаланган очракта;

5) 1999 елның 31 декабренә кадәр дәүләт теркәвен гамәлгә ашыра торган дәүләт теркәве органыннан гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу яки булмау турында гариза бирүче гаиләсенең һәр әгъзасы тарафыннан бирелә торган мәгълүматлар;

6) гариза бирүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның күчермәләре (1999 елның 31 декабренә кадәр);

7) керемнәр һәм мөлкәт бәясе турында мәгълүматлар»;

3) 2.6 пунктының икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) аерым затның элек булган (хәзерге) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

2) күчемсез милек объектына хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

3) күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

4) үлүне дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар;

5) яшәү урыны буенча торак урында теркәлгән гражданнар санын раслаучы мәгълүматлар;

6) инвалидлык турында мәгълүматлар;

7) гариза бирүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның күчермәләре (2000 елның 1 гыйнварыннан башлап);

8) торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында карар (граждан яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урында яшәгән очракта);».

4) 3.3.2 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тапшырылган документларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, шулай ук ведомствоара запрослар буенча алыначак документлар исемлеген күрсәтеп, гариза бирүчегә исемлек тапшыру.»;

5) 3.4.1 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Район хакимияте белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада кирәкле мәгълүматлар бирү турында запрослар җибәрә.»;

6) 3.6.1 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхакова йөкләргә

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов